ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**20.10.2025** **г.Чистополь** **№ 517**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2023, 2024, 2025 елларда Чистай муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча кыска вакытлы муниципаль планнарны раслау турында» 2022 елның 22 июнендәге 423 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 7 өлеше нигезендә, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2017 елның 20 мартындагы 155 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау турында»2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары ( Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.01.2015 №29, 02.09.2016 №612, 21.03.2017 №161, 29.12.2017 №1115, 25.12.2018 №1230, 03.05.2019 №376, 03.06.2019 №460, 03.03.2020 №165, 05.10.2020 №905, 21.07.2021 №634, 14.02.2022 №122, 02.09.2022 №952, 05.04.2023 №418, 29.05.2024 №375, 15.10.2024 №882 карарлары белән кертелгән төзәтмәләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырыла торган эшләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт ясауга муниципаль ярдәм күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2023, 2024, 2025 елларда Чистай муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча кыска вакытлы муниципаль планнарны раслау турында» 2022 елның 22 июнендәге 423 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 2023, 2024, 2025 елларда Чистай муниципаль районы территориясендәге күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарында:
1.1.1. Кыска сроклы планнарның төп максатларын һәм бурычлары II бүлегенең 10 абзацын төшереп калдырырга;
1.1.2. Кыска сроклы планнарның төп максатларын һәм бурычлары II бүлегенең 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Кыска сроклы муниципаль планнарны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 49486,90 квадрат метр булган 25 күпфатирлы йортта 1728 гражданның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш".
1.1.3. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның күләме IV бүлегенең таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | 2023-2025 еллардан барлыгы эшләр күләме | шул исәптән еллар буенча | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | Түбәләрне ремонтлау, шул исәптән вентилияләнә торган түбәне яңадан урнаштыру, түбәдә чыгу юлларын булдыру, түбәдә ремонтлау | кв. метр | 22070,0 | 5802,0 | 7424,0 | 108844,0 |
| 2 | Йорт эчендәге җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су агызуның инженер системаларын, шулай ук йорт эчендәге инженер системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны, шул исәптән: | пог. метр | 24774,0 | 6776,0 | 7063,0 | 10935,0 |
| | җылылык белән тәэмин итү | пог. метр | 12035,0 | 2138,0 | 4041,0 | 5856,0 |
| | кайнар су белән тәэмин итү | пог. метр | 2208,0 | 1042,0 | - | 1166,0 |
| | салкын су белән тәэмин итү | пог. метр | 4282,0 | 1442,0 | 1210,0 | 1630,0 |
| | су кертү | пог. метр | 5595,0 | 1935,0 | 1576,0 | 2084,0 |
| | газ белән тәэмин итү | пог. метр | 654,0 | 219,0 | 236,0 | 199,0 |
| 3 | Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | кв. метр | 4719,0 | 1264,0 | 1183,0 | 2272,0 |
| 4 | Фасадны ремонтлау | кв. метр | 30621,0 | 9031,0 | 11430,0 | 10160,0 |
| 5 | Гомуми мөлкәткә караган | кв. метр | 5255,0 | 1293,0 | 1609,0 | 2353,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | подвал бүлмәләрен ремонтлау | | | | | |
| 6 | Җылылыкны исәпкә алу төенен урнаштыру | данә | 1 | 1 | - | - |
| 7 | ГВСны исәпкә алу приборын урнаштыру | данә | 1 | 1 | - | - |
| 8 | ХВСны исәпкә алу приборын урнаштыру | данә | 5 | 3 | 2 | - |
| 9 | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 25 | 8 | 9 | 8 |
| 10 | Проект документациясенә дәүләт экспертизасын эшләү һәм уздыру | данә | 25 | 8 | 9 | 8 |

1.1.4. Ресурслар белән тәэмин итү V бүлегенең 2-5 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Кыска сроклы планнар чараларын финанслауның гомуми күләме 434 619 241,82 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:
- Татарстан Республикасы бюджеты - 168 977 657,65 сум;
- Чистай муниципаль районы бюджеты - 59 361 000,00 сум;
- урыннар милекчеләре акчасы - 206 280 584,17 сум.»;
1.1.5. Ресурслар белән тәэмин итү V бүлегенең таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанслау чыганаклары»

| № т/б | Финанслау чыганаклары | шул исәптән еллар буенча | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | Татарстан Республикасы бюджеты | 390898338,00 | 10398338,00 | 890981,65 |
| 2 | Чистай муниципаль районы бюджеты | 19787000,00 | 19787000,00 | 19787000,00 |
| 3 | Милекчеләр акчалары | 52351956,48 | 80727811,65 | 73200816,04 |
| | Барлыгы: | 112037294,48 | 140413149,65 | 182168797,69 |

1.1.6. Ресурслар белән тәэмин итү V бүлегенең таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2023, 2024, 2025 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга финанс чаралары күләме

| № т/б | Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Барлыгы 2023-2025 еллар буенча | шул исәптән еллар буенча (сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| А | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Түбәләрне ремонтлау, шул исәптән вентиляләнә торган түбәне яңадан | 247764256,44 | 56627976,36 | 78667770,53 | 112468509,55 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | урнаштыру, түбәдә чыгу юлларын булдыру, түбәдә ремонтлау | | | | |
| 2 | Йорт эчендәге инженерлык системаларын электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су түгү, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны ремонтлау яисә алмаштыру, шул исәптән: | 55058108,74 | 14392452,52 | 14563823,59 | 26101832,63 |
| | җылылык белән тәэмин итү | 29132318,85 | 5502214,95 | 8657051,33 | 14973052,57 |
| | кайнар су белән тәэмин итү | 3170944,12 | 1320355,19 | - | 1850588,93 |
| | салкын су белән тәэмин итү | 5872036,11 | 1977446,00 | 1717858,48 | 2176731,63 |
| | су кертү | 13076088,72 | 3548725,94 | 3273016,89 | 6254345,89 |
| | газ белән тәэмин итү | 3806720,94 | 2043710,44 | 915896,89 | 847113,61 |
| 3 | Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | 24765115,85 | 6047818,33 | 6157711,00 | 12559586,52 |
| 4 | Җылылыкны исәпкә алу төенен урнаштыру | 609435,80 | 10; 600; 80 | - | - |
| 5 | ГВСны исәпкә алу приборын урнаштыру | 6010,38 | 310210,38 | - | - |
| 6 | ХВСны исәпкә алу приборын урнаштыру | 1933274 | 1010131399,17 | 1071925,57 | - |
| 7 | Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә караган подвалларны ремонтлау | 1085289,31 | 167191,53 | 263862,91 | 654234,87 |
| 8 | Фасадны ремонтлау | 78520675,90 | 26694996,56 | 31884044,51 | 19941634,83 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Проект документациясенә дәүләт экспертизасын эшләү һәм уздыру | 20200603,54 | 5435241,48 | 6736590,90 | 8028771,16 |
| 10 | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 6112221,12 | 1630572,35 | 2067420,64 | 2414228,13 |
| | Барлыгы | 434619241,82 | 112037294,48 | 140413149,65 | 182168797,69» |

1.1.7. 1, 2, 3, 4 нче кушымталарны әлеге карарга 1,2,3,4 нче кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. «Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2023, 2024, 2025 елларда Чистай муниципаль районы территориясендәге күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау турында» 2022 елның 22 июнендәге 423 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 28 гыйнварындагы 27 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «https.//chistopol.tatarstan.ru» рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары итеп йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов